КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 сентябрь г.Казань № 989

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2020 ел, 17 июль, 603 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2020 ел, 17 июль, 603 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында цифрлы хезмәтләр күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында цифрлы хезмәтләр күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» сүзләрен «Татарстан Республикасында цифрлы хезмәтләр күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

«Татарстан Республикасы Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесен – мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы һәм техник операторы итеп;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгын – мәгълүмат системасы операторы итеп.»;

әлеге карар белән расланган «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

2. «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесенә бу карар үз көченә кергән көннән 60 көн эчендә, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән килештереп, «Татарстан Республикасында цифрлы хезмәтләр күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эше регламентын эшләргә һәм расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 17 июль, 603 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 13 сентябрь, 989 нчы
карары редакциясендә)

# «Татарстан Республикасында цифрлы хезмәтләр күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә «Татарстан Республикасында цифрлы хезмәтләр күрсәтү» дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Мәгълүмат системасы) эшен оештыру тәртибен билгели.

1.2. Мәгълүмат системасы – мәгълүматлар базаларындагы информация һәм аны эшкәртүне тәэмин итә торган мәгълүмат технологияләре һәм техник чаралар җыелмасы.

1.3. Мәгълүмат системасының эш регламенты – Мәгълүмат системасы операторы белән килештереп, Мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы (техник операторы) тарафыннан раслана торган, Мәгълүмат системасыннан файдалану мөмкинлеген бирү тәртибен һәм шартларын, физик зат турындагы белешмәдән файдалану мөмкинлеген оештыру тәртибен (физик зат тарафыннан шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире алу һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүне туктату тәртибен кертеп), үзара мәгълүмат алышуда катнашучыларның мәгълүмат куркынычсызлыгына карата таләпләрне билгели торган документ.

## 2. Мәгълүмат системасын булдыру максатлары

2.1. Мәгълүмат системасы түбәндәге максатларда булдырыла:

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системалары инфраструктурасы һәм аларның эшләвен тәэмин итү чыгымнарын оптимальләштерү;

гамәлдәге һәм яңа булдырыла торган мәгълүмат системаларында эшкәртелә торган мәгълүматларны нәтиҗәле файдалану.

## 3. Мәгълүмат системасының бурычлары

3.1. Мәгълүмат системасы түбәндәге бурычларны хәл итү өчен булдырыла:

төрле мәгълүмат системаларының үзара интеграциясен тәэмин итү исәбенә ведомствоара мәгълүмат алышуны оештыру, мәгълүматны «бер тапкыр кертү һәм күп тапкыр файдалану» принцибы буенча файдалану;

физик затның цифрлы профилен булдыру;

мәгълүмат системаларын һәм электрон исәпләү машиналары программаларын эшләгәндә һәм файдалануга керткәндә бердәм стандартларны куллану;

бу Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы бишенче абзацында күрсәтелгән оешмаларга физик затлар (Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар) турындагы белешмәне әлеге физик затларның ризалыгын алып файдалану мөмкинлеген оештыру.

## 4. Мәгълүмат системасы белән үзара бәйләнештә булу

4.1. Мәгълүмат системасы аша үзара мәгълүмат алышуда катнашучылар:

Мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы (техник операторы) – «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

Мәгълүмат системасының операторы – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;

Мәгълүмат системасыннан функциональ файдаланучылар – дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган органнар; муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган органнар; дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашкан, бу Нигезләмә кушымтасының 1 – 38 пунктларында күрсәтелгән физик зат турындагы белешмәдән файдалану мөмкинлеге бирелә алган ведомство буйсынуындагы оешмалары;

оешмалар – Мәгълүмат системасының эш регламенты нигезендә физик зат ризалыгы белән бу Нигезләмә кушымтасының 1 – 5, 10 – 13, 15 – 23, 25, 27, 28, 31, 32, 34 пунктларында күрсәтелгән һәм гражданлык-хокук шартнамәләрен, шул исәптән кредит шартнамәләрен төзү өчен, төзелгән гражданлык-хокук шартнамәләрен, шул исәптән кредит шартнамәләрен үтәү өчен физик затлар тарафыннан кирәкле гаризалар тутырылганда «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә физик затлар ризалыгы белән физик зат турындагы белешмәдән файдалану мөмкинлеге бирелә алган коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмалар.

4.2. Мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы (техник операторы):

Мәгълүмат системасын һәм аның элементларын модификацияләү буенча эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү), аңа техник ярдәм күрсәтү максатларында подрядчыларны (башкаручыларны) билгеләнгән тәртиптә билгели;

Мәгълүмат системасы операторы белән килештереп, Мәгълүмат системасының эш регламентын раслый;

мәгълүмат системасын булдыру, үстерү һәм техник тәэмин итеп тору һәм анда эшкәртелә торган мәгълүматны саклау чараларын үткәрүне тәэмин итә;

Мәгълүмат системасында шәхси мәгълүматларны эшкәрткәндә аларның конфиденциаль булуын һәм аларның куркынычсызлыгын тәэмин итә;

Мәгълүмат системасының һәм аның составына керә торган кайбер элементларның эшләвен тәэмин итә торган сервер һәм челтәр җиһазының, электрон исәпләү машиналары программаларының өзлексез эшләвен тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Мәгълүмат системасы белән эшләгәндә мәгълүмат куркынычсызлыгына карата таләпләрнең үтәлешен тәэмин итә;

Мәгълүмат системасының мәгълүматлар базаларындагы информацияне эшкәртүне тәэмин итә, шәхси мәгълүматны эшкәртү максатларын, эшкәртелергә тиешле шәхси мәгълүматларның составын, шәхси мәгълүматлар белән башкарыла торган гамәлләрне (операцияләрне) билгели.

4.3. Мәгълүмат системасы операторы:

Мәгълүмат системасын эксплуатацияләү эшен оештыра;

шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларын һәм эшкәртелергә тиешле шәхси мәгълүматларның составын, шәхси мәгълүматлар белән башкарыла торган гамәлләрне (операцияләрне) килештерә;

Мәгълүмат системасы белән үзара мәгълүмат алышуда катнашучыларның үзара мәгълүмат алышуына һәм үзара технологик бәйләнешенә карата һәм Мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы (техник операторы) тарафыннан белешмә алу һәм бирү тәртибенә карата таләпләрне билгели;

Мәгълүмат системасының эш регламентын килештерә.

## 5. Мәгълүмат системасының функцияләре

5.1. Мәгълүмат системасы түбәндәге функцияләрне башкара:

дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүче физик яки юридик затларны йә аларның вәкаләтле вәкилләрен (алга таба – гариза бирүче) идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне тәэмин итү;

«Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының үзара мәгълүмат алышуын һәм үзара технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация и аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы белән үзара бәйләнешләрне тәэмин итү;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гамәли программа интерфейсы технологияләре һәм (яки) ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы ярдәмендә ведомствоара электрон хезмәттәшлекне тәэмин итү;

мәгълүматны саклап тоту һәм дәүләт хезмәтләре яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органнарга; муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган органнарга; дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашкан ведомство буйсынуындагы оешмаларына алардан файдалану мөмкинлеген оештыру (физик зат турында белешмә исемлеге бу Нигезләмәнең кушымтасы нигезендә билгеләнә);

электрон формада дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының үзара мәгълүмат алышуын һәм үзара технологик бәйләнешен тәэмин итү;

гариза бирүчеләрнең профилен эшләү һәм электрон рәвештә, шул исәптән алдан күреп эш итү (проактив) режимында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны автоматлаштырылган ысул белән тутыру өчен Мәгълүмат системасында булган физик зат турындагы белешмәдән файдалану;

физик затның ризалыгын алып, коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмаларның «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә физик зат турындагы белешмәдән

файдалану мөмкинлеген оештыру – гражданлык-хокук шартнамәләрен, шул исәптән кредит шартнамәләрен төзү өчен, һәм (яки) төзелгән гражданлык-хокук шартнамәләрен, шул исәптән кредит шартнамәләрен үтәү өчен физик затлар кирәкле гаризаларны тутырганда (физик зат турында белешмә исемлеге (аннан файдалану өчен коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмаларга мөмкинлек бирелә алган) бу Нигезләмә кушымтасының 1 – 5, 10 – 13, 15 – 23, 25, 27, 28, 31, 32, 34 пунктларында билгеләнде).

5.2. Мәгълүмат системасында физик затларның шәхси мәгълүматларын эшкәртү «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 6. Мәгълүмат системасының составы

6.1. Мәгълүмат системасы бер-берсе белән үзара бәйләнештә торган берничә катламнан тора:

а) инфраструктура катламы: серверлар, мәгълүматларны саклап тоту системалары, челтәр җиһазы һәм башка җиһаз, шулай ук әлеге аппарат чараларының эшләвен тәэмин итә торган операцион системалар;

б) технологик катлам: электрон исәпләү машиналары өчен билгеле бер предмет өлкәсе белән бәйле булмаган бертип программалар (мәгълүматлар базалары белән идарә итү системалары, объект саклагычлар, программаны баланста тоту җайланмалары, хәбәр хатлары брокерлары һәм башка программа чаралары). Әлеге компонентларның кулланышын җәелдерү һәм аларны башкару өчен инфраструктура катламы кулланыла.

Мәгълүмат системасы электрон исәпләү машиналары өчен башка программаларны һәм мәгълүмат системаларын (Мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы (техник операторы), Мәгълүмат системасы операторы һәм Мәгълүмат системасының функциональ кулланучылары тарафыннан булдырыла торган мәгълүматлар базаларын кертеп) урнаштыру платформасы буларак кулланыла.

6.2. Мәгълүмат системасында урнаштырыла торган электрон исәпләү машиналары программалары һәм мәгълүмат системалары исемлеге, шулай ук аларның эш регламентлары Мәгълүмат системасы операторы тарафыннан раслана.

6.3. Мәгълүмат системасын формалаштыру Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт мәгълүмат системаларын булдыру, үстерү, файдалануга кертү, файдалану һәм файдаланудан алу, аларның мәгълүматлар базаларындагы информацияне алга таба саклап тотуга карата таләпләр турында» 2015 елның 6 июлендәге 676 номерлы карары белән расланган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 7. Мәгълүмат системасыннан файдалану мөмкинлеге

7.1. Мәгълүмат системасыннан файдалану мөмкинлеге Мәгълүмат системасының эш регламентында үзара мәгълүмат алышуда катнашучыларның билгеләнә торган вәкаләтләре нигезендә файдалану мөмкинлеге хокукын бүлү принцибы буенча аутентификация һәм авторизация чараларын кулланып тормышка ашырыла.

7.2. Мәгълүмат системасында мәгълүмат алышуда катнашучылар белән үзара мәгълүмат алышу һәм технологик бәйләнеш технологик һәм программа инфраструктурасы, Мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы (техник операторы) белән килештерелгән мәгълүмат алышуда катнашучылар арасында мәгълүматлар алмашу форматлары нигезендә электрон рәвештә рәсми сораулар җибәрү һәм җаваплар алу ярдәмендә аны интеграцияләү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 8. Мәгълүмат системасының мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү

8.1. Мәгълүмат системасының мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

8.2. Мәгълүмат системасы кысаларында мәгълүмат куркынычсызлыгын – рөхсәт ителмәгән файдалану мөмкинлегеннән, саклап тотыла һәм тапшырыла торган мәгълүматның тулылыгы һәм дөреслеге бозылудан саклауны тәэмин итү чаралары комплексы каралды. Мәгълүмат системасында мәгълүматның сакланышы программа һәм техник саклау чаралары һәм Мәгълүмат системасы белән эшләүгә карата таләпләрне үтәү буенча оештыру чаралары комплексы ярдәмендә тәэмин ителә.

«Татарстан Республикасында цифрлы хезмәтләр күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 сентябрь, 989 нчы карары редакциясендә)

Физик зат турында белешмә исемлеге

1. Физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), туу датасы, җенесе.
2. Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН).
3. Индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС).
4. Физик затның шәхесен таныклый торган документлары турында, шул исәптән физик затның яшәү урыны буенча теркәлү, яшәү урыны буенча теркәлү исәбеннән төшү турында, паспортның гамәлдә булуы (гамәлдә булмавы) турында, элек бирелгән паспортлар турында белешмә.
5. Физик затның фактта яшәү урыны.
6. Бер адрес буенча бергәләп тору урыны яки яшәү урыны буенча теркәлгән (миграция исәбендә торган) затлар турында белешмә.
7. Россия Федерациясе гражданлыгын алу турында белешмә.
8. Чит ил гражданына яки гражданлыгы булмаган затка яшәү төрен бирү яки аның гамәлдә булу срогын озайту турында белешмә.
9. Физик затның гаилә составы һәм аның ата-анасы белән бергә яшәү факты турында белешмә.
10. Күчемсез мөлкәт объектларының бердәм дәүләт реестрында физик затка караган күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмә.
11. Физик затка караган транспорт чаралары турында белешмә.
12. Россия Федерациясенең хезмәт законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән физик затның хезмәт эшчәнлеге һәм хезмәт стажы турында белешмә, иминият стажы, гражданны эшсез дип тану, гражданның хәрби хезмәттә булуы турында белешмә.
13. Хөкемгә тартылган (тартылмаган) булу һәм (яки) җинаять эше кузгалтылу факты булу (булмау) турында яисә җинаять эше туктатылу турында, розыскта булу турында белешмә.
14. Ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү, ата-ана хокукларын кире кайтару турында, ата-ана хокукларын чикләү, ата-ана хокукларын чикләүне гамәлдән чыгару, баланың гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда аны тартып алу турында, гражданның юридик хокукларын чикләү турында яки гражданның юридик хокуклары булмавын тану турында, Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында бирелгән законлы вәкилләр турында белешмә.

15. Гражданлык хәле актларын теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмә.

16. Физик затның никахлашуын һәм никахын өзүен дәүләт теркәвенә алу турында белешмә.

17. Гражданны пенсия (пенсия алды) яшендәге гражданнар категориясенә кертү турында белешмә.

18. Белем алу һәм (яки) квалификация турында документлар булу турында белешмә.

19. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан белешмә.

20. Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең статистика регистрында бирелгән белешмә.

21. Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында бирелгән белешмә.

22. Физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә кую (исәптән төшерү) турында белешмә.

23. Физик затның керемнәре, шул исәптән социаль, иминият түләүләре, алиментлары турында белешмә.

24. Физик затка компенсация түләү хокуклары турында белешмә.

25. Физик затның белеме турында белешмә.

26. Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелү кысаларында физик затның дәүләт пошлиналары өчен түләве турында белешмә.

27. Россия Федерациясе законнарын бозган өчен салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар түләү буенча физик затның бурычы турында белешмә.

28. Физик затка карата кузгатылган үтәтү эше буенча белешмә.

29. Физик затның дәүләт хезмәтләре яки муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле нотариаль таныкланган документлары турында белешмә.

30. Законнар белән җайга салына торган гамәлләрне кылу өчен физик затка бирелгән махсус рөхсәт кәгазьләре турында белешмә.

31. «Электрон формада дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының үзара мәгълүмат алышуын һәм үзара технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация и аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында авторизация үткәндә физик зат тарафыннан күрсәтелгән абонент номеры, электрон почта адресы.

32. Физик затның юридик зат, гамәлгә куючы (катнашучы) исеменнән ышаныч язуыннан башка эш итәргә хокуклы зат буларак юридик затларның идарә органнарында катнашуы турында, физик затны индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу турында, физик затны индивидуаль эшмәкәр буларак теркәү датасы турында һәм физик затның индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеге туктатылу датасы турында белешмә.

33. Иректән мәхрүм итү яки мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәүче физик затның җинаять-үтәтү системасы учреждениесендә булу урыны турында белешмә.

34. Нотариуслар һәм квалификация имтиханы тапшырган затлар реестрыннан өземтә.

35. Физик затның инвалидлыгы турында белешмә.

36. Физик затның мәҗбүри дәвалануда булуы турында яисә өч айдан артык дәвалануда булу факты турында белешмә.

37. Физик затның банк счетлары (вкладлары) турында белешмә.

38. Сәяси репрессияләргә эләккән физик затны аклау турында белешмә.